# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **09.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районының Керэш-Шуран авыл жирлеге составына керүче
Керэш-Шуран торак пунктына 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл жирлегенә керүче Керэш-Шуран торак пунктында гражданнар жыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Керэш-Шуран торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә, көндезге формада укучы студентларга 500 (биш йөз) сум күләмендә, үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Керэш-Шуран авылы янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүгә;
- Керэш-Шуран авылы мәдәният оешмалары хезмәтләре белән ял вакытын оештыру һәм халыкны тәэмин итү өчен шартлар тудыруга;
- Физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, Керэш-Шуран авылы жирлегендә рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыруга;
- Керэш-Шуран авылы жирлегендә рәсми мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыруга;
- Керэш-Шуран авылы жирлеген төзекләндерүне оештыруга;
- Керэш-Шуран авылында ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тотуга;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүгә, Керэш-Шуран авылы суларын чыгаруны оештыруга;
- Керэш-Шуран авылы жирлегенең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә;
- Керэш-Шуран авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыруга».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда , Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына һәм Керэш-Шуран авылы, Узэк урамы, 6А йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар жыенында рәислек итүче,
Керэш-Шуран авыл жирлеге башлыгы Р.Г.Сафиуллин